**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

28 гыйнвар, 2022 ел № 12 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. «Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2014 елның 22 июлендәге 32 номерлы, «Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 24 декабрендәге 64 номерлы карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Рәсми Татарстан” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ “Кадрлар сәясәте” бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы Ютазы
район Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин

Татарстан Республикасы
Ютазы район Советының
28 гыйнвар 2022 ел № 12
Карарына кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы җирле
үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы
вазыйфасын биләү өчен конкурс турында Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс уздыру тәртибе һәм шартлары билгеләнә.

2. Конкурс Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнарында вакантлы (муниципаль хезмәткәр биләмәгән) вазыйфасы булганда Ютазы муниципаль районы башлыгы күрсәтмәсе белән игълан ителә. Конкурс муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен уздырыла.

3. Конкурс үткәрелми:

1) сайланулы муниципаль вазыйфа биләүче зат вәкаләтләрен үтәүне турыдан-туры тәэмин итү өчен гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә;

2) вакытлы хезмәт шартнамәсе төзегәндә;

3) җирле үзидарә органы бетерелүгә, аның штаты кыскаруга (муниципаль хезмәт вазыйфасы кыскаруга) бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына билгеләнгәндә;

4) кадрлар резервында торучы муниципаль хезмәткәр (граждан) муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куелганда;

5) муниципаль хезмәткәр вазыйфаи үсеш тәртибендә муниципаль хезмәтнең югарырак вазыйфасына билгеләнгәндә;

6) штат берәмлеген бер җирле үзидарә органыннан яисә бер структур бүлекчәдән икенчесенә тапшырганда, әгәр элек бу вазифаны биләгән муниципаль хезмәткәр яңа төзелгән яңа вазыйфага, шул ук җирле үзидарә органының башка структур бүлекчәсенә күчсә;

7) җирле үзидарәнең бер үк органында бер вазыйфадан икенчесенә күчергәндә.

4. Конкурста катнашу хокукына 18 яшькә җиткән һәм әлеге вазыйфалар төркеме өчен гамәлдәге законнар белән билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары ия.

5. Конкурс уздыру һәм конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турындагы хәбәр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кадрлар сәясәте» бүлекчәсендә рәсми сайтында басылып чыга.

6. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы хәбәрдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) җирле үзидарә органының, вакантлы вазыйфаның тулы исеме;

2) әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга куела торган таләпләрне үз эченә алган конкурс уздыру шартлары;

3) конкурс уздыру датасы, вакыты һәм урыны;

4) әлеге Нигезләмәнең 8 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны, вакыты һәм күрсәтелгән документлар кабул ителә торган вакыт;
5) конкурс турында тулы мәгълүмат чыганагы турында белешмәләр (телефон, факс, электрон почта);
6) хезмәт килешүе проекты.

7. Конкурс уздыру турындагы хәбәр конкурс үткәрелгәнче 20 календарь көннән дә соңга калмыйча басылып чыга.

8. Конкурста катнашырга теләүче затлар конкурс комиссиясенә гариза бирә, аңа түбәндәге документлар теркәлергә тиеш:
1) үз куллары белән тутырылган һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнгән форма буенча имзаланган анкета, фотография белән;
2) паспортының яисә аны алмаштыручы документының күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);
3) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт шартнамәсе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;
4) белеме турында документның күчермәсе;
5) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документның күчермәсе, хезмәт шартнамәсе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;
6) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;
7) хәрби исәпкә алу документы күчермәсе - запаста торучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;
8) муниципаль хезмәткә керүгә тоткарлык ясый торган авыру булмау турында медицина учреждениесе бәяләмәсе;
9) граждан һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук аны идентификацияләү мөмкинлеген бирә торган мәгълүматларны урнаштырган сайтларның адреслары һәм (яисә) сайтларның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге битләре турында белешмәләр;
10) хөкем ителүе булмау турында белешмә.

9. Гариза биргән затка документлар кабул ителүе турында аларның исемлеге һәм кабул ителү датасы күрсәтелгән раслау кәгазе бирелә.

10. Граждан конкурста катнашуга вакантлы вазыйфага квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле, шулай ук муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә рөхсәт ителми.

Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнаштырудан баш тарткан очракта граждан әлеге карарга карата гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашучы теләсә кайсы вакытта үз гаризасын кире кайтарырга хокуклы.

11. Тәкъдим ителгән документларны кабул итү һәм тикшерү конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

12. Әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү конкурс уздыру көненә кадәр биш көн кала туктатыла.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданга аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

13. Конкурс Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының вакантлы вазыйфаларын биләүгә Бердәм конкурс комиссиясе тарафыннан уздырыла.

14. Конкурс вакантлы вазыйфаны биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфага квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

15. Тәкъдим ителгән документлар нигезендә Ютазы муниципаль районы муниципаль хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә Бердәм конкурс комиссиясе конкурста катнашуга кандидатлар кертүгә рөхсәт турында карар кабул итә.

16. Әгәр вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрү нәтиҗәсендә вакантлы вазыйфага квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаган булса, Ютазы муниципаль районы башлыгы Ютазы муниципаль районының вакантлы вазыйфаларын биләүгә Бердәм конкурс комиссиясе тәкъдиме буенча конкурсны кабат уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы.

Кабат конкурс уздыру турында карар шулай ук, әгәр Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бердәм конкурс комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатларның берсе дә вакантлы вазыйфага билгеләнү өчен кирәкле тавышлар санын җыймаган булса, кабул ителергә мөмкин.

17. Муниципаль хезмәтнең конкурста катнашуга кертелмәгән вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары өч ел дәвамында аларның язма гаризалары буенча аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Шушы вакыт узганчы документлар Татарстан Республикасы Ютазы район Советы архивында саклана, шуннан соң юк ителергә тиеш.

18. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкалар) кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән башкарыла.

19.Кандидат конкурс комиссиясе карарына гамәлдәге законнар нигезендә шикаять бирергә хокуклы.